РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» 05 2025 ел №491

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 14.11.2024 № 1006 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү уку-укыту программалары буенча өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны 2025 елда тукландыруны оештыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 № 273-ФЗ Федераль законы, Россия Мәгариф министрлыгының 18.11.2022 елның «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы карамагындагы федераль дәүләт мәгариф оешмалары тарафыннан оештырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны өйдә ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин итү тәртибен, шул исәптән ике тапкыр түләүсез туклануны акчалата компенсация белән алыштыру мөмкинлекләрен раслау турында» № 1001 санлы боерыгы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы районы прокуратурасының "Район башкарма комитетының 14.11.2024 елның № 1006 санлы карары белән расланган "2025 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны туклandыруны оештыру турында"гы нигезләмәгә" 18.04.2025 ел № 02-01-13 санлы протестына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының норматив хокукый актларын Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларны 2025 елда туклandыруны оештыру тәртибе турында Татарстан Республикасы Ютазы

муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында»гы 14.11.2024 ел, № 1006 санлы карары белән расланган Нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын өйдә алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны коры паек белән тәэмин итәргә яисә туклану өчен компенсацияне әлеге карарда билгеләнгән күләмдә ике тапкыр туклану бәясенә тигез акчалата эквивалентта түләргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

С.А. Абрамов
тел. 2-42-23